**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Ошторма-Юмья авыл җирлеге башлыгы**

**карары**

**2022 елның 11 ноябре** **№ 11**

**«Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 22 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Май урамы, 25а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 22 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Май урамы, 25а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. 2022 елның 22 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Май урамы, 25а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

4. 2022 елның 22 ноябрендә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Май урамы, 25а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлеге Югары Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Юмья авылының Тимер юл, Май, Тау асты урамнарында юлларны төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, су торбаларын урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Югары Юмья авылында янгын гидрантлары, янгын рукавлары, стволлар, переходниклар, колонкалар, мотопомпа сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәләгә ашыру;

- чишмәләрне төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Югары Юмья авылында сүүткәргеч челтәрләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын, су башнясын (ВНБ) ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, грунтны кул һәм экскаватор белән эшкәртү, торба үткәргеч урнаштыру, ремонтлау, бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, су башнясы өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, (материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- Югары Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту (кышын юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Югары Юмья авылы зираты территориясен карап тоту, ремонтлау, төзекләндерү һәм зират коймасы урнаштыру, күмү йортын төзү, урнаштыру, ремонтлау, чүп контейнерлары, моточапкыч, бензин пычкысы, генератор һәм инвентарь (көрәкләр, тырмалар, ломнар, баскычлар) сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета

документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- видеокамера сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

7. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Ошторма Юмья авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы С.В. Тимофеев